**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 30.01.2023** **№ 161**

# Җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турында

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Дөбъяз ав., Үзәк ур. 77а й., адресы буенча урнашкан 16:16:090102:67 кадастр номерлы 1826 кв.м мәйданлы, «ашханә урнаштыру өчен» рөхсәт ителгән файдалану төренә ия җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен «Кибет» рөхсәт ителгән файдалану төренә үзгәртергә.
2. «Татарстан Республикасы Биектау районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнә әлеге карарны теркәгән көннән алып ун эш көне эчендә Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына тиешле белешмәләр кертү өчен әлеге карарның күчермәсен җибәрергә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин